БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» 03 2024 ел № 107

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы буенча 2024 елның II кварталына гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының уртача бәясен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» турында 2017 елның 30 декабрендәге 1710 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» турында 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе дәүләт программаларының аерым чараларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү турында» дәүләт программасын раслау хакында» 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» эксперт-консультация советының «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2024 елның 23 гыйнварындагы 13 номерлы хаты һәм Балтач муниципаль районы торак комиссиясенең 2024 елның 9 февралендәге 2 номерлы карары нигезендә Балтач муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында 2020 - 2025 елларга яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында Балтач муниципаль районы территориясендә 2024 елның II кварталына гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының бәясен 34845 сум күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтына (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов